чара-чыганакларының берсе тәрҗемә дә яшәргә, камилләштерелергә тиеш. Шөкер, күрдек ки, бүген бит бездә, теләк булганда, омтылыш булганда ябышып ятарлык, уңай үзгәрешләр кертергә нигез булырлык фәнни, фәнни-гамәли кыйбла, тәҗрибә бар. Һәрхәлдә, Тәлгат Миңлебаевның, Флорид Әгъзәмовның тәрҗемә эшчәнлегенә керткән тырышлыгы нәтиҗәләренең файдасын бүген дә тоеп яшибез. Аларны яңа шартларда кабызып-яңартып кына җибәрергә кирәк. Кыскасы, бу юнәлештә хәлне объектив бәяләү, мөшкел хәлдән чыгу өчен кыю һәм ышанычлы ыргылыш ясау өчен яшьләргә элгәрләребезнең тәҗрибәсе өлге була алыр иде.

**Әдәбият**

1. Әгъзәмов Ф.И. Татар матбугатының үсеш этаплары // Тонус: Научно-публицистический альманах. Казань, 1996. №1. 90–97 б.

## НАСТАВНИК, ОБУЧАВШИЙ НА ЛИЧНОМ ПРИМЕРЕ

**И.М. Низамов,**
доктор филологических наук, профессор
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия),
E-mail: nizamil@yandex.ru

**Аннотация.** В данной статье автор рассматривает особенности публицистической и редакторской деятельности журналиста Ф.Агзамова.

**Ключевые слова:** Ф.Агзамов, творчество, татарская журналистика

**Summary.**The author considers peculiarities of publicistic and editorial work of the journalist F.Agzamov.

**Keywords:** F.Agzamov, creativity, Tatar journalism.

## ҮЗ ҮРНӘГЕНДӘ ӨЙРӘТҮЧЕ ОСТАЗ

Флорид Имамәхмәт улы Әгъзәмов белән без кордашлар идек; ярты гасыр диярлек журналистикада бергә эшләп, якыннан аралашып яшәдек. Ул миннән җиде айга өлкәнрәк иде. Көндәлек яшәештә без моны сизмәсәк тә, гадәт кушканча «абый», энем» дип дәшешмәсәк тә мин бу аерманы тоеп яшәдем. Хәзер уйлыйм: ул чыннан да бөтен яклап миннән өлкәнрәк, гомер буе миңа абый булган икән. Ә яшьлек мохите әлләни аермалы булмаган үзе – ул Башкортстанның Чакмагыш төбәгендә авылда үсеп, саф татарча шигырь, мәкаләләр яза башлап, аларны шундагы газетта бастырып; урта мәктәпне тәмамлап, күптәнге хыялы Казан университетына укырга кергән; мин – Татарстанның Казан артындагы авылында үсеп шулай ук татар телендә шигырь, мәкаләләр язып, аларны «Яшь сталинчы» газетында бастырып, аннары

Казан елга техникумында укып, аны тәмамлагач, Флоридның туган илендә, Агыйделдә штурман булып эшли башлап, язуны Уфада татарча чыга торган «Кызыл таң» газетында дәвам иттергәнмен, туган илем белән, анда чыккан газет-журналлар белән дә элемтәне өзмәгәнмен.

Университетны тәмамлагач, Флорид журналист эшенә шундук тотына – Питрәч район газетында. Башка газетларга да өлгерә. Күреп белмәсәм дә язмаларын күзәтә башлаганымны хәтерлим. Үзем дә «Кызыл таң» газетына эшкә күчеп, Башкорт университетының татар бүлегендә дә укыдым. Флорид та район газеты чирканчыгында озак булмады; башын калкыта, каләмен чарлый төшкәч, аны «Социалистик Татарстан»га эшкә алдылар. Андагы язмалары инде туган ягы Башкортстанга да, безгә дә таныш була башлады. Аның туган ягына тартылып, мөмкин булган саен кайтырга омтылуы табигыйдер, шул арада ике журналистның очрашуы бер-берсенә кардәш диярлек ике газет белән бәйләнешләре булуы да бик табигыйдер. Димәк ки, алтмышынчы еллардан ук без аның белән аерылгысыз аралаша башладык, иҗади, гаиләи дуслыгыбыз гомер буена сузылып, үрелеп китте. Ул еллардагы бәйләнешебез турында язганым бар иде инде. Әле менә шушы арада гына, архивны барлап утырганда, каләмдәшемнең «Кызыл таң»да басылган язмасын табып алдым. Без аны Флорид эш белән Башкортстанга кайткач, «Социалистик Татарстан»ның чыга башлавына 50 ел тулу уңаеннан сорап алган идек. Язма бүген дә әһәмиятен югалтмаган.

Безнең язмыш охшаш, әлләни аерма юк кебек тоелса да, бар икән! Флорид туган илен-төбәген бик тә яратып, гомер буе туган нигезен сагынып, аңа талпынып яшәсә дә кире кайтып төпләнә алмады. Мина, шөкер, туган илемә, Казаныма кайтып, гомеремне азагынача шунда үткәрергә насыйп булды. Бер килсә килә бит ул: мин Шәмси абый Хамматов, Флорид булышлыгы белән Казанга кайтып, «Социалистик Татарстан» газетында төпләнеп, Флорид белән шактый бергә эшләп алгач, Шәмси абый икебезне дә Мәскәүгә укырга җибәрде: аны Иҗтимагый фәннәр академиясенә, мине Югары партия мәктәбенә. Башкалада да дәрескә йөрүдән бигрәк күбрәк архивларда утырып, аралашып яшәдек. Ул тарих фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклап кайтты. Эшкә дә аны фәнни юнәлештә Казан университетына тәгаенләделәр. Мине Татарстан китап нәшриятенә бүлек мөдире итеп билгеләделәр; кайта кайтышка шул университетның татар теле бүлегенә аспирантурага кердем, журналистика бүлегендә дәресләр бирә башладым. Флорид белән тагын да якынаю моның белән генә түгел иде – фәнни темаларыбыз берникадәр аерылса да төп кыйблабыз бер – журналистика эшчәнлеге һәм фәне, бу һөнәргә укыту эше; аннары безне тәрҗемә эше дә берләштерә иде. Татарстан китап нәшрияте ул елларда тәрҗемә эшчәнлегенең үзәге иде, классикларның, хөкүмәтнең, партиянең иң җитди документ, әсәрләре шушында тәрҗемә ителеп бастырып чыгарыла иде. Флорид Әгъзәмов тәҗрибәле тәрҗемәче буларак бу җаваплы эшнең үзәгендә торды. Мин исә, сәяси-иҗтимагый әдәбият бүлеге мөдире буларак, шул эшчәнлеккә административ җитәкчелек итүче. Тәрҗемәгә бәйле

проблемалар икебезгә дә кагыла булып чыкты, аны бер үзәктә хәл итү кирәк дигән нәтиҗәгә килдек – КДУда журналистика факультетында тәрҗемә кафедрасы ачу нияте туды. Шуны да күздә тотыптыр инде мине университетка күчәргә кодаладылар. Ул вакытка инде мин филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклап, университетта төп курсларны укыта башлаган идем. 1987 елның ноябреннән татар журналистикасы кафедрасында өлкән укытучы сыйфатында (аннары, шунда доцент, профессор вазыйфаларында) турыдан-туры аның мөдире Флорид Әгъзәмов кул астында эшләп киттем. Шуннан инде без Флоридның вафатынача аерылышмадык.

Журналист, җәмәгать эшлеклесе, галим, педагог Флорид Имамәхмәт улы Әгъзәмов киң колачлы, төрле юнәлешле хезмәт кешесе иде. Безне ул бик күп нәрсәгә өйрәтеп калдырды. Аның тарихи йөзен, эшчәнлеген ачыклау-анализлауга багышланган фәнни, гамәли чараларның, әйтик, менә шушындый конференцияләрнең аңа карата төрле темаларны колачлавы табигый хәлдер. Үземә дә моңарчы да хезмәттәшебез, остазыбызның тәрҗемәи хәлен төрле өлкәдә, төрле юнәлешләрдә ачыкларга, тасвирларга туры килгәне булды. Галим һәм педагогның төрле юнәлешләрдәге эшчәнлеген тирәнтен анализлап, киләчәк буыннарга калдыру юлында бөтен мөмкинлекләрне, шул җөмләдән менә бүгенгедәй фәнни-гамәли чараларны да файдалану әһәмиятле. Бу юнәлештә безгә инде мәгълүм гомуми бәяләмәләрне, ачыкланган мәсьәләләрне кабатламыйча, остазыбызның мул тәҗрибәсенең яңа кырларын ачарга, яңа мәсьәләләрнең чишелешенә җитди әһәмият бирергә кирәк. Шәхсән үзем менә бүгенге чара турында ишеткәч, аны оештыручыларга ихластан рәхмәт әйтеп, остазыбызның әле яктыртылып бетмәгән якларын күз алдына китерергә тырыштым: бар икән бит әле мөгаллимебезнең бүген барыбызга да кирәкле булып та игътибар биреп җиткерелмәгән сыйфатлары! Мәсәлән, аның төп коралыбыз татар телен куллану мәсьәләсенә мөнәсәбәте, бу кыйблада эшчәнлеге турында тирәнтен уйланырга, үзенә бер система белән фәнни анализ ясарга кирәктер. Бүгенге чыгышымның темасы да шул.

Килешегез, бу – бүген дә барыбызга да кирәкле, фәнчә әйтсәк, актуаль мәсьәлә. Туган телдә сөйләм оештыру мәсьәләсе татар журналистикасы өчен гомумән дә беркайчан да өзелеп, тукталып тормый торган, табигый бер көнүзәк мәсьәлә булырга тиешлеге бәхәссез булып та бүген исә ул үзенә бер сәяси-иҗтимагый, хәтта милләткүләм, дәүләткүләм проблема булып, татарча әйтсәк «чи төенгә» әйләнеп китте. Хәтта дәүләти титул исемен йөрткән республикада, Конституция белән татар теле дәүләт теле дип рәсмиләштерелгән шартларда шушы канунны үтәп яшәр өчен кешенең туганнан алып (яследән югары уку йортынача) гомере буена шул телне өйрәнү, куллану мөмкинлеге, тәртибе булмавы сәер, аптыраrлык хәл түгелмени, хәтта милләт исеме белән аталган, хәтта «гуманитар», «филология», «әдәбият», «тел, лингвистика», «мәдәният, культура», «сәнгать», «театр» төшенчәләре белән бәйле урта, югары укыту йортларында да туган тел сәясәте, укыту системасы дәүләти-катгый тәртиптә алып барылмый; бәхәсләр, каршылыклар тынмый, көчәя генә бара. Һәрхәлдә

олуг казанышыбыз – татар теленең дәүләт теле булу фактын халык файласына хезмәт иттерү, телебезнең киләчәге өметле булсын өчен эшләтергә вакыттыр бит инде.

Киләчәктә бу изге максатка ирешергә чынлап торып алынганда милләтпәрвәр Ф.Әгъзамовның бөтен гомерен биргән тәҗрибәсе нык таяныч була ала. Нинди тәҗрибә турында әйтәбез? Башта бер факторга игътибар итик әле: татар журналистының эшчәнлеге гомер-гомергә өч кыйблалы булды: үзе язды, бүтәннәр язганны төзәтеп-редакцияләп бастырды, тәрҗемә белән шөгыльләнде. Өч кыйблада да төп коралы – татар теле. Бу бәхәссез хакыйкать Ф.Әгъзәмовның тәҗрибәсендә ничек чагыла? Сорауга үзе нигезен салган, озак еллар җитәкчелек иткән факультетның кырык еллыгы уңаеннан җәмәгатьчелеккә биргән хисабындагы мондый юллар җавап була ала түгелме: «...Соңгы елларда Республиканың үзендә дә, аннан читтә дә милли журналистиканың интенсив үсеш алуы татар телендә эшләүче кадрларга кискен ихтыяҗ тудырды. Шуңа күрә дә аларны хәзерләү системасын камилләштерүдә җитди адымнар ясарга кирәк булды. Факультетның татар бүлегендә укытуның махсус планы төзелде, программалар яңартылды. Журналистика белән бәйле дисциплиналарны татарча укытуга күчерү төгәлләнеп килә. Татар телен һәм әдәбиятын укыту курсларына сәгатьләр арттырылды, татар халкы тарихын өйрәнүгә махсус курслар тәкъдим ителде; алар – алдыңгы иҗтимагый-сәяси карашлар, музыка сәнгате, исламның рухи тәрбиядә әһәмияте һәм башка мәсьәләләрне колачлый. Программалар татар телендә дә бастырыла, уку-укыту ярдәмлекләрен һәм дәреслекләрне дә татарча чыгару планлаштырыла». Хисапта декан шулай ук журналистика фәне буенча башкарыла торган эшләрнең татар теле, тәрҗемә теориясенә бәйле булуын, шушы чорда якланган докторлык диссертацияләренең дә (И.Низамов, В.Гарифуллин) нәкъ менә татар телле матбугат буенча булуын искәртә. Ул шулай ук факультетта 1996 елдан «Тонус» исемендә фәнни-публицистик альманах чыгып килүен дә сөенеп, горурланып белдерә. Чыннан да, аның башлангычында чыга башлаган альманах фәнни дөньяда әһәмиятле яңалык булды. Аның һәр санында «Татар журналистикасы» дигән рубрика астында дистәләрчә татарча мәкаләләр басылды. Остазыбызның үзенең хезмәтләре дә еш басыла иде.

Гомуми сүзләр белән «бизәлгән» хисапларны кайсы гына җитәкче бирмидер, диярсез. Килешәм, арада хәтта татар теле мохитендә эшләп яшәргә тиешле коллективта да татарча бер сүз белән аралашмаган, татар телен чыннан да дәүләт теле итү өчен кыл да кыймылдатмаган җитәкчеләр аз түгел. Тик бу Флоридка берничек тә кагылмый. Аңа карата бөтенхалык фикерләвендә барлыкка килгән «үзе уйнап өйрәтүче тренер» дигән атаклы хакыйкать аның бу эшчәнлегенә дә турыдан-туры карый: ана телендә камил аралашып, язып, чын үрнәк-өлге күрсәтеп ул татар теленең бөтен яшәешебездә дәүләт теле була алу мөмкинлеген исбатлады, бу кыйблада киләсе буыннар да ышанычлы атласын өчен юл күрсәтте.

Флорид Имамәхмәт улының бу үрнәк-өлгесенә диккать беләнрәк, фәнни нигездә карыйк әле. Гомумән дә бу проблеманы киң масштабта, системага салып күзәтеп –анализлап була. Берничә аспектта өйрәнергә кирәк тә: 1) ул – татар телендә уйлап, татар телле һәм катнаш телле коллективта аралашып, туган телдә иҗат итүче, ягъни төрледән-төрле сөйләмдә – жанрларда язучы, сөйләүче (безнең шартларда андыйлар аз түгел – журналист, язучы, артист, рәссам, укытучы, табиб, җитәкче, чиновник-түрә, депутат, сәүдәгәр, эшмәкәр һ.б.); 2) ул – шушы төр коллективта җитәкче вазыйфасын башкаручы (рәсми документларны, эш кәгазьләрен үзе татарча яза, редакцияли, тәрҗемә итә; бу юнәлештә башкаларга җитәкчелек итә: административ һәм фәнни-гамәли чараларны оештыра, алып бара, гомумән эштә, җитәкчелектә ана телендә аралашуның (язу, сөйләү) үрнәген күрсәтә; 3) ул – гуманитар һөнәрләре белгечлеге буенча махсус урта һәм югары уку йортларында ана телендә укыту тәҗрибәсе туплаган, студентларга, аспирантларга, диссертация якларга әзерләнүчеләргә ана телендә фәнни җитәкче булган белгеч; 4) ул – шушы юнәлештә татарча да публицистик, фәнни-популяр, фәнни хезмәтләр (дәреслек, уку кулланмасы дәрәҗәсендәге) авторы. Шушы төр иҗат әсәрләренә татар теленә таянып фәнни анализ ясаган, рецензияләр язган, дәреслек, кулланмаларга, диссертацияләргә бәя биргән белгеч; 5) ул – татар журналистикасы нигезләре, тарихы, милли үзенчәлекләре, тәэсир чаралары турында укучылар, студент, аспирантларга, гаммәви аудиториягә фәнни фикерләү методикасы белән әзерләнгән лекцияләрен, дәресләрен татарча җиткерүче, туган телдә мәгариф, мөгаллимлек юнәлешендә көндәлек эш башкару тәҗрибәсе туплаган, йөзләрчә шәкерт укытып, өйрәтеп чыгарган тәҗрибәле педагог, галим; шушы темага татарча фәнни, фәнни-популяр хезмәтләр язып, шул темага язылган хезмәтләргә бәя биреп, җыелыш-мәҗлесләрдә, фәнни конференцияләрдә, чараларда туган телдә даими чыгышлар ясап, белгечләр хәзерләп калдырган олуг мөгаллим; 6) Ул – гомумән дә, шушы кыйбладагы һәр төр иҗтимагый-сәяси, педагогик-тәрбияви хезмәтнең, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә үстерү юлында башкарыла торган эшчәнлеккә кагылган һәр гамәл турында, аның барышы, хәле турында тирәнтен анализ ясаган, фәнни нигездә бәяләп, иҗтимагый яссылыкта җәмәгатьчелеккә җиткергән, аның игътибарын җәлеп итү, аны хәрәкәткә китерү өчен укыту-тәрбияләү эшчәнлеге алып иҗатчы, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр.

Остазыбызның тәҗрибә хәсиятен менә шушы тәртип-система белән барларга тотынсак, кайбер юнәлешләрдәге эшчәнлек сыйфатлары, хезмәтләре берникадәр өйрәнелгәнен ачыкларбыз. Моңарчы үткәрелгән фәнни-гамәли чараларда кайбер нәтиҗәләр дә җиткерелде. Тик аларны барлау әлегә җитәрлек түгел. Бүгенге күзәтүләребез бәлки шул җитешсезлекне берникадәр капларга ярап куяр:

– остазыбызның аралашуда үзенең шәхси сыйфатларыннан, туган телнең йогынты көченнән файдаланып бүтәннәргә ничек тәэсир итүе турында

хезмәттәшләреннән, шәкертләреннән еш ишетергә туры килә. «Осталар остазы» җыентыгында хезмәттәшләре һәм шәкертләре М.Мәрдиева, В.Гарифуллин, Л.Пивоварова, Г.Шәрәфетдинев, Р.Сәгъдиев, И.Низамов, Р.Фәттахов, Ф.Садриев, А.Галиева, Р.Галиева, Э.Мозаффарова, З Хафизова һәм башкалар аның тәэсири сыйфатлары турында фикер уртаклашканнар иде. Башка чыганаклардан бүтән авторларның да остазга рәхмәт хисләрен күреп, ишетеп торабыз. Менә шушы язманы әзерләп утырганда да газетта («Ватаным Татарстан», 2015, 16 декабрь) күренекле журналист Гөлсинә Хәбибуллинаның саллы язмасын укыдым – укытучы хезмәтенең әһәмияте турында яза, чын педагогларны тәрбияләү эшендә үрнәк булырлык шәхесләребез барлыгына мисал итеп Флорид Әгъзәмовны да китерә: «...Кечкенә генә аңлашылмаучанлык, берәр проблема булса да һәрчак ярдәм итәчәгенә ышанып, мөрәҗәгать иткән ...Флорид абый безне дә исемләп, районлап хәтерли иде. Бездән соң укучылар аркылы сәламнәр әйтүенә, уртак танышлардан минем хакта, әни хакында сорашуына гаҗәпләнә идем...». Янә Чаллыдан күренекле журналист Нурия Вилданова журфакта укыганда хәтерләп калган старосталары истәлегенә җыр тапшыруны сорап Татарстан радиосына язган хатында Флорид абыйсын да телгә ала, «чын дуслык ул студент елларында, аннан соң портфель дуслыгы», дип әйткән иде, шул сүзләре онытылмый, ди.

Болар бит искергән хатирәләр түгел, бүгенге яшәеш белән бәйле ихтыяждан туган уйланулар, көндәлек кирәкле нәтиҗәләр.

Журналистның, җитәкченең эшендә туган телдә аралашу дигәндә без күз алдында аның шушы телдә язу осталыгын, үз мисалында язарга өйрәтү тәҗрибәсен тотабыз. Бу өлкәдә Ф.Әгъзәмовның тәҗрибә байлыгы мулдан. Безгә әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Шәхсән үзем аның язу остаханәсендә фельетончы һәм тәрҗемәче «мастер-класс»ларын аерып алып өйрәнү кирәклегенә ышанып, шул яссылыклардагы әсәрләрен махсус өйрәнеп, анализлап, нәтиҗәләрен укучыларга җиткерә алдым. Үзе язган журналист, язучы яхшы белә: бу төр иҗатларга теләсә кем алына алмый, башта иҗтимагый-сәяси җанрларның нигез төрләрендә (хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик жанрлар) каләм чарларга кирәк. Ф.Әгъзәмов асылда фәнни, фәнни-популяр, фәнни-публицистик сөйләм остасы. Шул ук вакытта ул без әле телгә алган журналистик җанрларның тасвири характердагыларын язган каләмдар. Мәсәлән, бүген студентларга осталык дәресенә күнегү өчен аның остазы Гази Кашшаф турында «Игелекле кеше» дигән тасвирнамәсен анализларга тәкъдим итеп булыр иде. Аның фәнни, фәнни-популяр әсәрләренең сөйләм үзенчәлекләрен анализлаганнан соң, менә бу сәнгати-публицистик әсәрдәге лексик, грамматик һәм дә синтаксик чараларга диккать итү кирәкледер. «Кем белә, бәлки мин дә бүлек мөдире һәм мөхәррир урынбасары буларак, Гази ага әсәрләренә кыскартып шактый зыян китергәнмендер. Әмма үпкәләп, авыз турсайтып йөрми иде үзе» (185 б.). «...Мөдир вазыйфаларын Гази ага башкара иде. Ул безне якты йөз белән каршы алды.

– Әйдә, әйдә, төкле аягың белән!– дип өстәл артыннан чыгып, җылы итеп күреште» (185 б.). Гади сөйләм чараларының ничек урынлы кулланылуына игътибар иттегезме?

Тәҗрибәле журналистның бу юнәлештәге иҗат алымнарын анализлаганда, методик ярдәм булырлык тәкъдим дә әйтә алабыз икән: ул татарча да публицистик, фәнни-популяр (дәреслек, уку кулланмасы дәрәҗәсендәге) фәнни хезмәтләр авторы. Шушы төр иҗат әсәрләренә татар теленә таянып фәнни анализ ясаган, рецензияләр язган, дәреслек, кулланмаларга, диссертацияләргә бәя биргән белгеч, дигән идек. Менә хәзер без аның әсәрләрен тел ягыннан бәяләгәндә, үзенең үк фәнни тезисларына, киңәшләренә таяна алабыз. Әйдә, кайберләренә тукталып алыйк. Мәсәлән, Ф.Әгъзәмовны фәнни, журналистик даирә жанр нәзариясенә дә өлеш керткән галим дип белә. Ә жанр инде ул сөйләм дигән сүз, ягъни һәр җанрда тел куллану үзенчәлекле. Ф.Әгъзамов журналистика жанрларына карата да моны таный. Яшь хәбәрчеләр өчен чыгарылып, бик озак еллар дәреслек хезмәтен үтәгән «Хәбәрче буласың килсә...» мәҗмугасында ул «Отчет» (Хисап) һәм «Интервью» жанрларына махсус билгеләмә бирә, бу жанрларның нәкъ менә милли үзенчәлекләрен ачыклый. Шул җөмләдән, әлбәттә инде, тел куллану үзенчәлекләрен дә искәртә. Әйтик, «интервью язган вакытта әңгәмәченең фикерләү манерасын, сөйләм үзенчәлеген сакларга тырышу бик мөһим», ди (46 б.).

Очерк җанрына карата уйланулары тагын да дәлиллерәк. «Үзәктә – кеше» дигән хезмәтендә галим очеркның фәнни асылын, эчтәлек хәсиятен төшендереп биргәндә, әлбәттә инде, очеркның асыл билгесе – сәнгати-сурәтилекнең мәҗбүри булуын кисәтә, ә моңа бит иң әүвәле тел чаралары белән генә ирешелә. «Художестволы сурәтләү чаралары очерк героеның образын, һәрхәлдә, аның кайбер сыйфатларын тоемлы итеп, җанлы итеп, индивидуаль кабатланмас итеп гәүдәләндерергә, аның эчке дөньясына, уй-хисләре дөньясына тирәнәтен үтеп керергә булыша. Әлбәттә, моннан публицистика чаралары образлы сурәтләү чараларын чит итә икән, автор фикерләрен маңгайга бәреп, коры итеп сөйләп чыгуга гына кайтып кала икән, дигән тәэсир калмасын. Юк, публицистика теле образлы сурәтләү чараларын да эченә ала, дөресрәге, алардан башка йөрәккә үтеп керә, акылны кузгата торган публицистика теле була алмый.» (29 б.).

Нәзари әһәмиятле бу йомгак-тезисын ул күренекле очеркчы Мәрди Рафиков иҗаты мисалында ясаса да, бу хактагы уйлануларына башка тәҗрибәле очеркчыларның иҗатына таянып та дәлилле итә: «...һәр әдипнең, һәр публицистның әле үз язу манерасы, үзе яраткан алымнары була. Әйтик, русның күренекле очеркистларыннан А.Аграновский, Г.Радов публицистик сурәтләү чараларына күбрәк өстенлек бирәләр шикелле. Бездә андыйлар рәтенә Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Хәмзә Зарипов, Илдар Низамовларны кертергә булыр иде» (32 б.).

Шушы хезмәтендә үк ул әлеге закончалыгының аерым очеркчыларга карата ничек чагылуын тирән анализ, ышанычлы дәлилләр белән тасвирлап бирә.

Г.Ахунов, М.Зарипов, Ш.Рәкыйпов, Р.Вәлиев, Р.Хисмәтуллин очерклары мисалында шул чор очеркларының сәнгати тасвир чараларын һәм алымнарын ачып бирергә тырыша. Кайбер авторлар барысы да эчтәлек, вакыйга, факт хәл итә диләр, шул төп факторларның ничек, нинди чаралар белән, сүрәт алымнары белән тасвирлавына җитәрлек диккать итмиләр. Ф.Әгъзәмов эчтәлек белән аны бәян итү чарасының турыдан-туры бәйле булуын дәлилләр белән исбатлап бирә. «Р.Вәлиев әсәреннән яшьлек, күтәренке рух, юмор, җыр бөркелеп тора. Әсәрнең юморга, җор сүзгә, мәзәккә өртелгән булуын аеруча басым ясап әйтәсем килә. Ялгыз кеше шаян сүзле була алмый. Шаяртырга коллектив кирәк. Сәламәт булмаган коллективта шулай ук шаяртырга урын юк. Җор сүз өчен, җор кыланыш өчен әйбәт коллектив кирәк, күңел көрлеге кирәк, яшьлек кирәк» (106 б.).

Минем очеркларны анализлаганда («Илдә мин дә сандугач» җыентыгындагыларны), тәэсир чаралары турында сүз алып барганда, детальләрнең үзенчәлекле булуы, контрастлык дигән алымны оста куллану тезисын алга куя. Аңлашыла булса кирәк, бу алымнар, һичшиксез, турыдан-туры сөйләм кору, тел мөмкинлекләрен тоемлау, аларны нечкә белү белән бәйле. Флоридның минем менә шул кыйбладагы алымнарны үрнәк итеп куясы килгән, күрәсең.

Сизгер укучым чамалап алгандыр, остазның әлеге фикерләүләре бер жанр кысаларыннан чыгып, тулаем публицистика, әдәбият чикләрен үтеп керде шикелле. Әйе, ул дөрес тоемлый: инде әйткәнебезчә, ул – телебезне сәнгатьнең төрле тармакларында шул җөмләдән нәфис әдәбиятта куллану нәзариясендә дә үзен сынаган, кирәкле нәтиҗәләр ясаган галим дә. Моны дәлилләр өчен, бер генә мисалга тукталып алыйк. Кулыбызда Шәмси Хамматовның «Газета һәм әдәбият дуслыгы» басмасы (Казан: Тат.кит.нәшр., 1979). Китапта, исеменнән күренгәнчә, «Ватаным Татарстан» газетының (димәк, «Эшче», «Кызыл Татарстан», «Социалистик Татарстан» газетларының) алтмыш ел буе әдәбият мәсьәләләрен ничек яктыртуы анализлана. Әлбәттә, инде анда ана теле мәсьәләләрен дә, аларга турыдан-туры кагылмаса да, искә алынмыйча мөмкин түгел. Ә Флоридның монда нинди катнашы бар, диярсез. Бар икән шул. Әле нинди генә катнашу! Китапта газетның әдәбият өлкәсендә алтмышынчы-җитмешенче еллардагы эшчәнлеге анализлана. Бу чорда газетта әдәбият, сәнгать язмалары өчен баш мөхәррир урынбасары Ф.Әгъзамов җаваплы була. Икенчедән, китапның махсус редакторы Ф.Әгъзәмов икән бит. Димәк ки, тел мәсьәләләрендә дә авторның махсус редактор белән фикердәш булуы аңлашыладыр. Шунысы да бар: автордан бераз гына аермалы буларак, тәҗрибәле редактор, фән кешесе дә буларак, гомумиләштерүләргә көчлерәк игътибар итә. Менә газета гамәлгә ашырган тел сәясәтенә карата китапта ясалган кайбер күзәтү, гомумиләштерү, нәтиҗәләргә мисаллар: «Шулай итеп, Татарстанның милли телдәге төп газетасы 1918–1930 елларда хезмәт ияләрен Коммунистлар партиясенә, Совет властена бирелгәнлек рухында, патриотизм идеяләре рухында тәрбияләүдә партиянең актив булышчысы иде» (44 б.); «Г.Кашшаф «Әдәби әсәрләрнең сыйфаты өчен» дип исемләнгән мәкаләсен

китапларның теленә багышлый, К.Нәҗми, Б.Сирин, Х.Туфан, М.Сөндекле шигырьләренә туктала. Авторның төп фикере телдә купшылыкка, абстракт төшенчәләргә, баш әйләндергеч ребус җөмләләргә каршы юнәлтелгән» (64 б.). «... Татар телендә чыккан фронт газеталары белән элемтәдә торылды, махсус сәхифәләр алмашу гадәткә керде» (120 б.). «Кайвакыт редакция летучкаларына язучылар, тәнкыйтьчеләтр дә чакырыла. И.Гази, Г.Бәширов, галимнәр И.Гыйззәтуллин, Х.Курбатов, Б.Мифтахов, Г.Ахунҗанов, В.Хаков, К.Сабиров һәм башкаларның газетада әдәбият мәсьәләләренең яктыртылышы, теле турындагы төпле фикерләре журналистлар өчен бик файдалы булды» (144 б.).

Шөкер, остазыбызның гомумиләштерүләргә мондый сәләте бер ноктага төенләнеп калмаган. Без инде аның аерым жанрлар, аерым сөйләм төрләрендә тел кулланууны күзәтү нәтиҗәләрен телгә алдык. Аларда иҗат эшчәнлеге туган тел белән турыдан-туры бәйле булганга, бу кыйблада аның хезмәтләрен өйрәнүдә без дә өлеш кerткәнебез булды. Аерым алганда, без Флорид Әгъзәмовның КФУда журналистлар тәрбияләүдә туган тел белән бәйле курсларны укытуда үзенең керткән яңалыклары турында, бу юнәлештә ниләр-ниләр башкарганын бәян иткәнебез булды. Аннары, инде үзенең шәхси иҗатына килгәндә, без аның юмор-сатира юнәлешендәге әсәрләренең сурәт чараларын анализлап, махсус мәкалә яздык. Аннары, галимнең тууына 75 ел тулу уңаеннан оештырылган фәнни-гамәли конференция уңаеннан, без Флорид Әгъзамовның тәрҗемәче эшчәнлегендә ана теле белән эш итү үзенчәлекләрен анализлап чыгыш ясадык, бу максатта тупланган, бүген дә яшь журналистларга кирәкле материалларны матбугатта, җыентыкта бәян иттек.

Шулай да остазыбызның тел белән бәйле иҗат хәзинәсен әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе икән. Хәтерләсәгез, Флоридның бала чагыннан ук шигырь язуын искәрткән идек. Бу – очраклы түгелдер. Мондый сәләте аның тел тоемлаудагы шәхси үзенчәлегенең гомер буе аерылгысыз булуын да искәртәдер. Телгә, сөйләмгә мөнәсәбәтен ачыкларга теләсәң кешенең тумыштан, әни сөте белән бирелгән фигыль-холкын истә тотарга кирәк. Аны бик яхшы белгән, гомер буе аралашкан каләмдәше, фикердәше, аралашып яшәгән кеше, берничә хатирә язган Гарәф абый Шәрәфетдинев тә аның ике сыйфатына игътибар итә: бала чагыннан ук шигырьләр язуына; ихластан җырлавына. «Ул Салават ариясен сузып җырлый башласамы – сулышсыз калып, дөньяны онытасың. Аның моң тавышы әллә кайлардан ук, бик эчкәрге тирәннән үк агылып чыга. Моңлы тавышына үзенчә бер төсмер, аерым аһәң өстәү өчен, ул, күзләрен яртылаш йомган хәлдә, бөтен йөз чырае белән, көй агышына иягенең бераз калтырауларын да кушып, хисләнеп-хисләнеп җырлый» (14 б.).

Гарәф абый фикерләвенчә дә мондый сәләтен кеше ана телен нечкә тоемлау, аның аһәңеннән сурәт ясый белү осталыгы булганда гына тормышчан итә ала. Аның янә дә бер тормышчан, бүген дә кирәкле фикере: «телнең әһәмиятен аңлау ул милләт өчен хәстәрләнү хисе белән бергә үрелеп бара. Ә милләт ул белемсез, матбугатсыз, сәхнәсез, үз телле радио, телевидениесез, һәм инде милли мәктәпсез, югары уку йортсыз була алмый. Әгъзәмовның журналистика бүлеген аерым

факультет итеп ачу өчен күпме иза чигеп йөрүен һич онытасыбыз юк. Teләгенә ирешге бит тәки. Ул студент яшьләр өчен татарча гәзит-басма чыгаруны да башлап йөрүчеләрдән булды. Бу басма «Мәгърифәт» газеты. Баштагы чорында ул университет күләмендә чыгарыла иде...».

Үзебездән дә өстик: ул башта «Ленинчы» исеме белән университет газеты буларак чыкты. Флорид аның баш редакторы иде. Берүк вакытта ул әле кайбер татар газетларының, «Татарстан» журналының редколлегия әгъзасы да иде. Моны ул дәрәҗә саклар өчен түгел, ә бәлки университетта нәзарияне өйрәткән шәкертләренә гамәли эшләрендә дә булышлык итү өчен эшләде. Аларда үз әсәрләрен бастырып та ул шәкертләренә сабак бирә иде.

Инде шигырьгә әйләнеп кайтсак, аңа ул беркайчан да битараф булмады. Шагыйрьләр иҗатына игътибарлы иде. Факультетта укучылар арасында, аны тәмамлап журналист булып эшләүчеләр арасында шагыйрьләрнең байтак булуы моңа ышанычлы мисалдыр. Күптән түгел «Мәгърифәт» газетының элекке теркәмәсен күзәткәндә, бер ачыш ясадым: газетның киләчәк язмышы өчен кайгыртып, аның «атасы» газетка, гомумән, әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә талантлы яшьләрне җәлеп итү өчен төрле алым, чаралар кулланган: әйтик, яшь талантларны тәкъдим итүдә үзе дә катнашып, ул чагында инде Башкортстанда да, Татарстанда да абруе үсә барган Рим Идиятуллинны да тәкъдим итеп, аның шигырь тупламасына кереш сүз язып, бу шагыйрьгә генә хас үзенчәлекләрен ачып бирә алган.

Менә шушы без санап киткән үзенчәлекле өлкәләрдә сөйләм оештыру нечкәлекләрен оста белгән иҗатчы ул тел куллануның гомуми нигезләрен, бүгенге хәлен төпле белергә тиештер. Чыннан да, остазыбыз, инде әйткәнебезчә, бүгенге яшәебезнең һәр төр иҗтимагый-сәяси, педагогик-тәрбияви хезмәтнең, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә үстерү юлында башкарыла торган һәр төр эшчәнлеккә кагылган һәр гамәл турында, аның барышы, хәле турында тирәнтен анализлап, фәнни нигездә бәяләп, иҗтимагый яссылыкта җәмәгатьчелеккә җиткереп, аның игътибарын җәлеп итү, аны хәрәкәткә китерү өчен укыту-тәрбияләү эшчәнлеге алып бару, шушы максатка фәнни, фәнни-популяр хезмәтләр иҗат итү, җәмәгати чаралар оештырып, анда чыгышлар ясау, шушы кыйбладагы мәсьәләләрне киң җәмәгатьчелек игътибарына җиткереп, аларның актив хәрәкәт итүенә ирешү осталыгына ия булган иҗатчы, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр иде. Соңгы елларда аның фикерләү колачына республикада татар телен куллануның гомуми торышы, аны дәүләт теле итү бурычының үтәлеше; журналистика һәм ана теле мәсьәләләре керде.